Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге Советы

## КАРАР

«02» октябрь 2017 ел. № 58

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» гы 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 23 мартындагы «Җирле референдум турында» 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Кышлау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, 2017 елның 22 сентябрендәге «Референдум үткәрүне оештыру турында» 16 номерлы Кышлау авыл җирлеге башкарма комитеты карары, «2017 елның 22 сентябрендәге «Референдум үткәрүне оештыру турында» 57 номерлы Кышлау авыл җирлеге Советының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советы карар **бирде:**

1. 2017 елның 19 ноябренә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2018 елда үзара салым кертү өчен 18 яшькә җиткән, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган Кышлау авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрү белән килешәсезме?:

1. Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Кышлау, Яңа Өҗем авылларында урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау;

- Кышлау авылы территориясен чистарту;

2. Кышлау авылында балалар мәйданчыгын төзекләндерү һәм җиһазлар сатып алу;

3. Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- Кызыл Утар авылы зираты территориясен киртәләп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу,

– Яңа Өҗем авылы зиратын чистарту, төзелеш материаллары алу.

ӘЙЕ ЮК»

3. Кышлау авыл җирлегенең сайлау комиссияләренә, гамәлдәге законнар нигезендә, «Кышлау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.

4. Аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны экономияләү очрагында, әлеге акчалар планлаштырылган эшләрне башкару өчен акча җитәрлек булмаган юнәлешләрне финанслауга юнәлтелә.

5. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру, «Әтнә таны» район газетасында бастырып чыгару һәм http://atnya.tatarstan.ru рәсми сайтка урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль
Районы Кышлау авыл җирлеге башлыгы Шакирова Р.Ф.

Совет Кшкловского сельского поселения
Кышлау авыл җирлеге Советы
ИНН 1610000620